КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 декабрь г.Казань № 1143

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 929 нчы карары белән расланган Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 929 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 740 нчы; 2021 ел, 29 май, 389 нчы; 2022 ел, 22 август, 874 нче; 2023 ел, 20 гыйнвар, 26 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, 2023 елның 21 декабреннән 31 декабренә кадәрге чорда тәэмин ителгән сөт өчен 2024 елда бирелә торган субсидия күләменең исәп-хисабы буенча белешмә кәгазе.»;

13 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«K – агымдагы финанс елына балалар ризыгы җитештерүче белән сөт тәэмин итү шартнамәсе буенча агымдагы елның 1 гыйнварыннан 20 декабренә кадәр субсидия алучы тарафыннан балалар ризыгы җитештерү өчен тәэмин итәргә планлаштырыла торган сөтнең физик авырлыгы, кг;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2024 елда 2023 елның 21 декабреннән 31 декабренә кадәрге чорда тәэмин ителә торган сөт өчен субсидия бирелә.

2023 елның 21 декабреннән 31 декабренә кадәр тәэмин ителә торган сөт өчен субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны Министрлыкка тапшыра.»;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2023 елның 21 декабреннән 31 декабренә кадәрге чорда тәэмин ителә торган сөт өчен 2024 елда субсидия алу өчен субсидия алучы Министрлыкка күрсәтелгән чор өчен, әлеге пунктта каралган документларны теркәп, субсидия бирү турында гариза тапшыра.»;

15 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2023 елның 21 декабреннән 31 декабренә кадәрге чорда тәэмин ителә торган сөт өчен субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия күләме ($W_{m1}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{m1} = P_1 \times (S_1 - S_f),$$

монда:

$P_1$ – 2023 елның 21 декабреннән 31 декабренә кадәрге чорда балалар ризыгы җитештерү өчен субсидия алучы тарафыннан фактта тәэмин ителгән сөтнең физик авырлыгы;

$S_1$ – 2023 елның 21 декабреннән 31 декабренә кадәрге чорда сөтнең уртача базар бәясе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Тәржемәче: А.М.Сәгыйтова